**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**

---

РЕШЕНИЕ КАРАР
24 ноябрь 2023 ел № 17

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - җирле үзидарә органы вәкаләтләренең үтәлешен тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирлеге Уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат.»;

2) 5 статьяда:

5.3 пунктның 5 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 пунктының 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 6.3 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 7 статьяның 7.1 пунктында:

1 пунктчаның дүртенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчаның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчаның өченче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына, кайда» сүзләрен «кайда» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчаның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә, кайда» сүзләрен «кайда» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 8 статьяда:

8.4 пунктының беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктының икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.7 пунктта «муниципаль хезмәт» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.»;

8.8 пунктта «муниципаль хезмәт» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.»;

6) 10 статьяда:

10.2 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.6 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.9 пунктының 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратын» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.13 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.15 пунктының икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.21 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10.24 пунктны өстәргә:

«10.24. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан уздырыла.»;

7) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 11.27 пункт өстәргә:

«11.27. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс Поселения Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләр тапшыру турындагы килешүләр нигезендә конкурс уздыру буенча Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан уздырыла.»;

8) 18 статьяның 18.1 пунктындагы 4 пунктчасында «һәм мәҗбүри социаль иминият» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 22 статьяның 22.6 пунктында:

22.6.2 пунктчада икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«а) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба - хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) тарафыннан яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;»;

22.6.2 пунктчада түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«е) коррупциячел хокук бозуларны кылу турында хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең докладында, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасында аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән генә (ышанычны югалту сәбәпле эштән алу рәвешендә җәза кулланудан тыш);»;

түбәндәге эчтәлекле 22.6.16 пунктча өстәргә:

«22.6.16. Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар тикшерүе тарафыннан таныла икән.»;

10) 24 статьяда:

24.5 пунктта «ышанычлы булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «муниципаль хезмәт» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 24.5.1 пунктчасын өстәргә:

«24.5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге статьяның 24.5 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы рәисе И.З.Хабибуллин